| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ЛЕНИНОГОРСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>«ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27.10.2025 г.Лениногорск № 24

Лениногорск муниципаль районы Советының 2022 елның 20 маендагы 33 номерлы карары белән расланган муниципаль милектәге җир кишәрлекләренең яисә дәүләт милке чикләнмәгән, сату үткәрмичә гамәлгә ашырыла торган җир кишәрлекләренең бәясен билгеләү тәртибенә үзгәреш кертү турында

«Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 31 июлендәге 353-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Лениногорск муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Лениногорск муниципаль районы Советының 2022 елның 20 маендагы 33 номерлы карары белән расланган муниципаль милектәге җир кишәрлекләренең яисә дәүләт милке чикләнмәгән, сату үткәрмичә гамәлгә ашырыла торган җир кишәрлекләренең бәясен билгеләү тәртибенә түбәндәге үзгәреш кертергә:

2 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) бакчачылык яисә яшелчәчелек коммерциягә карамаган ширкәтенә, мондый ширкәт әгъзасына бирелгән җир кишәрлегеннән барлыкка килгән бакча җир кишәрлеге яисә яшелчә җир кишәрлеге;».

2. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru)бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы муниципаль берәмлегенең Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы муниципаль казна учреждениесе рәисенә йөкләргә.

Лениногорск муниципаль<br>районы Башлыгы,<br>Совет рәисе

М.Н.Гирфанов